# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге
торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**19 ноябрь 2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРА:

1. Мәсьәлә буенча карарны таныргa:«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә,1,2 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
   1. - Воровский исемендәге совхоз бистәсе һәйкәлен (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территориясен төзекләндерү (мемориалны реконструкцияләү (өч статуяны ремонтлау), мәңгелек утны яңарту, брусчатка салу, койманы алыштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү)

3.Әлеге карарны Воровский исемендәге авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Воровский исемендәге авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: Елхов В.П.